КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 октябрь г.Казань № 918

Торак урын һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен фактта арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик (максималь) индексларыннан артып киткән очракта, гражданнарга компенсация түләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнарның коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләве күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру турында» 2014 ел, 30 апрель, 400 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Торак урын һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен фактта арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик (максималь) индексларыннан артып киткән очракта, гражданнарга компенсация түләү тәртибен расларга.
2. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән компенсацияне исәпләү һәм түләүне оештыру функционалын эшләү һәм гамәлгә кертүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин